РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

_17.11.2025 №962-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 11 октябрендәге 1621-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 11 октябрендәге 1621-п номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре булып торучы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм (яисә) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның б) пунктчасының алтынчы абзацын «бирү» сүзләреннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү башкарылган көннән дә соңга калмыйча,» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 2 пунктның б) пунктчасын түбәндәге эчтәлекле алтынчы һәм җиденче абзацлар белән тулыландырырга

«бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү ;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча

штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентын билгеләү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча халыкка җиткерергә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Кәримов